# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Көчек торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**27.11.2020** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Көчек торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2020 елның 27 ноябрендә 09:00 сәг, 2020 елның 27 ноябрендә 11:00 сәг һәм 2020 елның 27 ноябрендә 14:00 сәг уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2021 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Көчек торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булган һәр кешедән 400 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1.Көчек авылында бишенче линия урнаштыру, лампаларны, дроссельләрне, фонарьларны ремонтлау һәм яктырту өчен материаллар сатып алу.

2. Көчек авылында К. Маркс, Ленин, Колхоз тыкрыгы, Тукай тыкрыгы урамнарына вак таш сатып алу һәм җәю.

3. Көчек авылында юлларга хезмәт күрсәтү- кардан чистарту.

4. Көчек авылында Яңа һәм Ленин урамнары буенча материаллар сатып алу һәм суүткәргеч челтәрне алыштыру.

5. Көчек авылында янгын сүндерү машинасын карап тоту, ремонтлау (штаттан тыш хезмәткәрләргә хезмәт килешүе буенча түләү, янгын җиһазлары һәм стволлар сатып алу).

6. Көчек авылында су башнясын койма белән әйләндереп алу өчен материаллар сатып алу.

7. Көчек авылында җирләү урыннарын карап тоту (зират коймасын яңарту).

8. Көчек авылында Бөек Ватан сугышы һәйкәлен сатып алу һәм урнаштыру.

9. Көчек авылында кешеләр тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч янаучы авария хәлендәге һәм корыган яшел үсентеләрне кисү.

10. МТЗ-82 тракторын карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү, трактор өчен өстәмә асылмалы җиһазлар сатып алу (төягеч һәм ротор чапкыч).

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 445 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 254 кеше, бу 57 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 254 катнашучы тавыш бирде;

"КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Көчек торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. 2021 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Көчек торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 400 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертергә.

3.Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1.Көчек авылында бишенче линия урнаштыру, лампаларны, дроссельләрне, фонарьларны ремонтлау һәм яктырту өчен материаллар сатып алу.

2. Көчек авылында К. Маркс, Ленин, Колхоз тыкрыгы, Тукай тыкрыгы урамнарына вак таш сатып алу һәм җәю.

3. Көчек авылында юлларга хезмәт күрсәтү- кардан чистарту.

4. Көчек авылында Яңа һәм Ленин урамнары буенча материаллар сатып алу һәм сууткәргеч челтәрне алыштыру.

5. Көчек авылында янгын сүндерү машинасын карап тоту, ремонтлау (штаттан тыш хезмәткәрләргә хезмәт килешүе буенча түләү, янгын җиңнәре һәм стволлар сатып алу).

6. Көчек авылында су башнясын койма белән әйләндереп алу өчен материаллар сатып алу.

7. Көчек авылында җирләү урыннарын карап тоту (зират коймасын яңарту).

8. Көчек авылында Бөек Ватан сугышы һәйкәлен сатып алу һәм урнаштыру.

9. Көчек авылында кешеләр тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч янаучы авария хәлендәге һәм корыган яшел үсентеләрне кисү.

10. МТЗ-82 тракторын карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү, трактор өчен өстәмә асылмалы җиһазлар сатып алу (төягеч һәм ротор чапкыч).

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Авыл җирлеге башлыгы Р.Ә.НУРМӨХӘММӘТОВ